ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 107-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 107-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 399-VII ДС

проект

Татарстан
Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 92 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда «хисап кварталы тәмамланганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча, хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә торган дүртенче квартал хисаплылыгыннан гайре» сүзләрен «хисап кварталы тәмамланганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяда:

а) 1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү;

б) 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 41 статьясында каралган тәртиптә тикшерүләр үткәрү.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба - 33-ФЗ номерлы Федераль закон) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү мөмкинлеген һәм тәртибен билгели торган (19 статья), шулай ук җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары эшчәнлеген тикшереп тору һәм күзәтчелек итү (77 статья) турындагы нигезләмәләре үз көчен югалткан дип танылды. Күрсәтелгән нигезләмәләрнең дәвамчанлыгы 33-ФЗ номерлы Федераль законның шундый ук хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган 33, 34 һәм 41 статьяларга кертелгән нормалар белән саклана.

Закон проекты белән «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 66-ТРЗ номерлы Закон) преамбуласына, 9 статьясындагы 1 пунктының өченче абзацына һәм 3 пунктының өченче абзацына, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга сылтама күрсәтү өлешендә үзгәрешләр кертелә.

33-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 6 өлешенең 5 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектының җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен бирүне күздә тотучы законында җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе булырга тиеш.

ТРЗ номерлы законның 8 статьясының гамәлдәге редакциясендә җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт төзелеш күзәтчелеге өлкәсендәге вәкаләтле органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары билгеләнгән. Бүгенге көндә Татарстан Республикасында барлык объектлар төзелеше өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп эскроу счетларында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Төзүче тарафыннан күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучыларның

акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзелеш проектларын гамәлгә ашыруның якынча графикларын һәм шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен үтәү турында хисап бирү тәртибенең 4 пункты нигезендә төзелеш проектының Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыручы органына Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 12 октябрендәге 656/пр номерлы боерыгы белән расланган җыелма тупланма ведомостенде төзүче тарафыннан өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын төзүгә җәлеп иткәндә төзүче тарафыннан «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 15□ статьясында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, мондый акчаларны эскроу счетларында урнаштыру юлы белән, контроль органына хисап бирелми.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, 33-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 6 өлешенең 5 пункты нигезендә җирле үзидарә органнарыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисапларны үз вакытында алу һәм тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны нәтиҗәле тикшереп торуны гамәлгә ашыру максатларында закон проекты тарафыннан 66-ТРЗ номерлы Законның 8 статьясында җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисапларны бирү сроклары үзгәртелде.

Закон проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслауны таләп итмәячәк.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортны төзү өчен кооператив әгъзаларының акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.